ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

пр. Строителей, д. 12, г. Нижнекамск, 423570

Төзүчеләр пр., 12-нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

10.10.2022 г. № 700

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында белем алучы балалары булган, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү чаралары турында

«Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» Россия Федерациясе Президентының 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы, Түбән Кама муниципаль районы Уставының 45 статьясы нигезендә, төп гомуми белем бирү программаларын һәм балалар өчен өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында белем алучы балалары булган, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның гаиләләренә өстәмә социаль ярдәм чаралары күрсәтү максатларында, Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизацияне игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның балаларына түбәндәге социаль ярдәм чараларын билгеләргә:

1) башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирүнең белем бирү программасын гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучы гражданнарның югарыда күрсәтелгән категория балаларын тукландыру буенча ата-ана кертемнәрен түләүдән азат итү;

2) өстәмә гомуми үсеш программаларын гамәлгә ашыручы Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе карамагындагы гомуми белем бирү оешмаларында һәм өстәмә белем бирү учреждениеләрендә

белем алучы югарыда күрсәтелгән категориягә керүче гражданнарның балаларын, өстәмә түләүле белем бирү хезмәтләре күрсәтүләренә түләүне дә кертеп, өстәмә белем бирү хезмәт күрсәтүләре өчен түләүдән азат итү.

2. «Татарстан Республикасы «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең бюджет һәм финанслар департаменты» муниципаль казна учреждениесенә (Логинова С.Н.) Түбән Кама муниципаль районы бюджетында каралган акчалар чикләрендә, әлеге карарның 1 пункты нигезендә, Түбән Кама муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә.

3. Түбән Кама муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары җитәкчеләренә:

3.1. әлеге карарның 1 пунктындагы 1 пунктчасында күрсәтелгән балалар белем ала торган:

1) ата-аналардан (законлы вәкилләрдән) түләүсез кайнар ризык белән тәэмин итү турында гаризалар кабул итү эшен оештырырга,

2) укучыларга туклануны оештыруны тәэмин итү,

3) кирәк булганда, махсус медицина күрсәткечләре буенча өйдә белем алучы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларга азык-төлек җыелмалары бирүне оештырырга;

3.2. әлеге карарның 1 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән балалар белем ала торган:

1) ата-аналардан (законлы вәкилләрдән), өстәмә түләүле белем бирү хезмәтләре күрсәтү өчен түләүне дә кертеп, өстәмә белем бирү хезмәтләре күрсәтү өчен түләүдән азат итү турында гаризалар кабул итү эшен оештырырга,

2) өстәмә түләүле белем бирү хезмәтләре күрсәтүне дә кертеп, өстәмә белем бирү хезмәтләре күрсәтүне тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре һәм Түбән Кама районы хәрби комиссарына (Ситдыйков Г.Ф.) Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизацияләү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар исемлеген, соңыннан - Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәтне тәмамлаган гражданнар исемлеген Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсенә (Гарифуллин А.Х.) җибәрүне тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

5. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсенә (Гарифуллин А.Х.):

Татарстан Республикасы Түбән Кама шәһәре һәм Түбән Кама районы хәрби комиссарыннан (Ситдыйков Г.Ф.) әлеге карарның 4 пункты нигезендә кергән белешмәләрне балалар өчен төп гомуми белем бирү программаларын һәм өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы ведомство карамагындагы Түбән Кама муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларына тапшыруны тәэмин итәргә;

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизацияне игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү

буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарның балаларына әлеге карарның 1 пунктында каралган социаль ярдәм чарасын тиешенчә гамәлгә ашыруны контрольдә тотуны гамәлгә ашырырга.

6. Әлеге карарның 1 пунктында каралган социаль ярдәм чарасы Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизацияне игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә гражданның Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәт үтү чорына билгеләнә дип билгеләргә.

7. Җәмәгатьчелек һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән элемтә бүлегенә әлеге карарны Түбән Кама муниципаль районы Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

8. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2022 елның 10 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

9. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.Г.Мәхмүтовка йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы,
Җитәкченең беренче урынбасары Р.Ф.Булатов